| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

___________________ №__________

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының
җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган
автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү
буенча 2017-2022 нче елларга төзелгән
муниципаль программасына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының, 2016 нчы елның 28 нче октябрендәге 1328-п номерлы “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү буенча 2017-2022 нче елларга төзелгән муниципаль программасын раслау турында”гы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү буенча 2017-2022 нче елларга төзелгән муниципаль программасына, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– Программа паспорты таблицасында “Программаны финанслау күләмнәренең еллар һәм чыганаклар буенча бүленеше” юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | 2017 – 2022 нче елларда Программаны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты хисабыннан финанслауның гомуми күләме 85 474,998 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2017 нче елда – 15 978,625 мең сум;<br>2018 нче елда – 15 136,410 мең сум;<br>2019 нчы елда – 14 259,963 мең сум;<br>2020 нче елда – 13200,000 мең сум;<br>2021 нче елда – 13600,000 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | 2022 нче елда– 13300,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (Чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджеты турындагы карары нигезендә ачыкланачак.<br>Экономияләнгән акчаларның калган өлешен ел саен юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча чаралар үткәрү өчен җибәрергә. |

2. 3 нче таблицада финанслау күләмен һәм чыганакларын (мең сум) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Саба муниципаль районы бюджеты,

Барлыгы 85 474,998, шул исәптән :
2017 нче ел – 15 978,625;
2018 нче ел – 15 136,410;
2019 нчы ел – 14 259,963;
2020 нче ел – 13200,000;
2021 нче ел – 13600,000;
2022 нче ел – 13300,000.

әлеге программаның 4 нче таблицасында тәкъдим ителгән финанс чараларын бүлү нигезендә”.

3. 4 нче таблицада:

- 2019 дигән графада:
- «3732,896» саннарын «5392,859» саннарына алмаштырырга;
- «12600,000» саннарын «14259,963» саннарына алмаштырырга.

- 2020 дигән графада:
- «2100,123» саннарын «2000,123» саннарына алмаштырырга ;
- «13300,000» саннарын «13200,000» саннарына алмаштырырга.

- 2021 дигән графада:
- «2136,858» саннарын «2436,858» саннарына алмаштырырга;
- «13300,000» саннарын «13600,000» саннарына алмаштырырга.

4. Әлеге карарны Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы И.Б.Таиповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р. Ишниязов